МБДОУ "Солнышко"

# Нурчыклар

*Буа районы "Кояшкай" балалар бакчасы гәҗите*

**№9 Май, 2021 ел**



## БӨЕК Җиңү көне мөбарәк булсын!

Кадерле Бөек Ватан сугышы ветераннары!

Тыл хезмәткәрләре! Сугыш елы балалары!

Хөрмәтле милләттәшләр!

Илебез Бөек Җиңүнең 76 еллыгын бәйрәм итә. Җиңү көне безгә миллионнарның каны һәм җаны бәрабәренә яулануы белән бөек, изге һәм кадерле.

Бүгенге санда


1. Җиңү бәйрәме
2. Чыгарылыш кичәсе
3. Бәйгедә катнашу


Сугыш тәмамланганга 76 ел үтсә дә, хәтер яши, хәтер мәңгелек. Ватан өчен дәһшәтле көрәштә кан койган ветераннарның яралары да гомерлек. Тән яралары төзәлсә дә, җан яраларының сыкрауларын, газиз ирләрен яу кырында югалткан толларның йөрәкләре сулкылдауларын, ә сугыш елы балаларының әрнү-сагышларын оныта торган түгел...

Без, сугыштан соң туган буыннар, бүген Сезнең алда баш иеп, тиңдәшсез батырлыгыгызга, рухыгызның ныклыгына сокланабыз. Бүген дә сафта булуыгыз белән горурланабыз. Бай тормыш тәҗрибәгез, зирәк киңәшләрегез белән яшь буында туган җиргә мәхәббәт, Ватанга хөрмәт тәрбиялисез. Барысы өчен дә зур рәхмәт Сезгә! Сезгә сәламәтлек, гаилә иминлеге телим. Дөньялар тыныч булып, иминлектә балаларыгыз, оныкларыгызның кадер-хөрмәтендә яшәргә Ходай насыйп итсен.

*Иң изге теләкләр белән, балалар бакчасы җитәкчесе Э.З.Әбүзәрова*





## *Җиңү көне*

Бүген бәйрәм! Күздән яшь тамса да,
Без бәхетле – аяз күгебез.
Саклап калсак иминлекне җирдә,
Аяз булыр килер көнебез.







# "Сау бул, инде бакчабыз!"







Йөрәк түрендә җуелмас эз калдырган иң якты хәтирәләр кеше тормышының кайсы чорында күбрәк очрый икән? Мөгаен, чыклы үләннәрдә яланаяк йөргән, әти-әни белән җитәкләшеп бакчага килгән гамьсез, кайгы борчуларсыз балачактадыр.

Менә безнең балалар өчен дә дулкынландыргыч та, шатлыклы да һәм моңсу да бәйрәм көнебез килеп җитте. Моңсу, чөнки күптәннән көткән, әмма безнең өчен бик тиз килеп җиткән көн бу. Бәхетле, үзенең гаилә бәйрәмнәре, әти-әнинең уртасында, аның бармакларына тотынып, адымнарына өлгерергә тырышып йөгергән, әкияттәге тормышны чынбарлык итеп кабул иткән чиста балачак белән саубуллашу көне.

Бакча белән саубуллашу көне,<br>
Ул гаҗәеп моңсу, күңелле.<br>
Шундый көн бу – олы бәйрәм үзе,<br>
Үзгәртә дә куя тормышны.<br>
Баш очыннан ак болытлар ага,<br>
Ак болытлар – сезнең балачак.<br>
Балачакка кире кайтып булмый<br>
Алар шулай ап-ак калачак.<br>
Ак болытлар – сезнең балачак









## "Минем гаиләм-минем байлыгым"

“Кояшкай” балалар бакчасының өлкән төркемендә тәрбияләнүче Вәлиев Эмиль Халыкара гаилә көненә багышланган "Минем гаиләм-минем байлыгым" дип исемләнгән Республика фәнни-гамәли конференция - проектлар конкурсында Гран - при яулады. Эмиль "Гаилә елъязмасы" тикшеренү эше белән чыгыш ясады, анда ул үзенең гаиләсе, якын туганнары тарихы турында сөйләде



# "Иң яхшы билингваль балалар бакчасы" бәйгесе

"Билингваль" - ике телле дигәнне аңлата. Бу очракта республикада дәүләт телләре булып исәпләнгән-татар һәм рус телләре турында сүз бара.

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан оештырылган "Иң яхшы билингваль балалар бакчасы" конкурсы да шуларны күздә тотып оештырыла. Бердән конкурста көч сынап карау мәктәпкәчә тәрбия бирүдә яңа методик алымнар кулланууга этәрсә, "Иң яхшы билингваль балалар бакчасы" исеменә ия булу - бакчаның материаль-техник базасын ныгыта.





































# Башваткычны чиш!





Әйдә, Елмай белән Шүркәгә бирелгән башваткычтан киемнәр эзләп карыйк.Моның белән шакмактагы хәрефләр ярдәмендә өстән-аска, сулдан-уңга, уңнан-сулга язылган сүзләрне табып сызарга кирәк. Рәсемдәге киемнәрнең кайсыларын кызлар, кайсын егетләр кия?









| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| К | У | Л | Ы | К | П | Ә | Л | Т | Ә |
| Ү | Я | К | К | Ә | Ш | Ф | Б | И | Я |
| Л | М | Ә | И | Т | А | Р | А | К | Л |
| И | Т | Е | Ч | А | Л | Ф | Л | Й | Ә |
| У | Т | К | Ф | У | Б | А | К | К | Ә |
| Н | Ш | Ә | Л | Т | А | Ү | П | Ә | Л |
| А | К | Л | О | Б | Р | Ш | Г | А | Л |
| А | Л | Ъ | Я | Ч | И | К | У | Т | С |
| Р | А | С | П | К | Т | Е | О | Е | К |
| А | Ф | А | Н | Ы | Ч | К | Б | А | Ш |

























«Нурчыклар» гәҗитен гамәлгә куючы:
Татарстан Республикасы Буа шәһәренең катнаш төрдәге “Кояшкай” балалар бакчасы” муниципаль бюджет учреждениесе

Редколлегия әгъзалары:
Гиниятуллина Д.Р.

Безнең адрес:
422430, Буа шәһәре,
Арефьева урамы, 13 йорт

Тел. (843)743-13-09
E-mail: colnush-bua@mail.ru